## Сөям туган телемне

Әни диеп тел ачылсын
сөйләшик туган телдә.
әби-бабай бүләк иткән,
телебез якын безгә.

Хәлең ничек, исән-саумы
диеп сәламнәр бирик.
туган телдә матур итеп
һәрчак сөйләшә белик.

Тукай, Җәлил, Туфаннарның
шигырьләрен өйрәник.
Туган телне гомер буе
күңелләрдә яшәтик.

Кушымта:
Туган телдә җырлап, биеп
яшәү шундый күңелле.
Милләтемнең бөртеге мин
Сөям туган телемне!